“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”

# Чишмә башы

№ 5
Март

**Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча гәҗит**

## *Әниләрнең җылы кочагы!*




Балагызның берәве сез,

Гаиләнең йөрәге сез,

Иминлекнең терәге сез,

Һәркемнең иң кирәге сез.

Әни... якты кояшка тиң, иң кдерле кеше. Дөньяда бәлки шулкадәр якын, ягымлы, ярдәмче кеше юктыр. Кеше кайда гына булса да, ни эшләсә дә, иң кирәк урын – әни янында, туган йортта. Ничә яшьтә булса да, һәркем үкереп елаган вакытта әнинең юатучы йомшак кулларын хәтерли. Башны сыйпап, бишек җырларын көләүче, кайгы-шатлыкларны уртаклашучы, гомер таянычы ул әни. Ул һәрберебез өчен иң кадерле, иң яхшы, иң матуры, гомумән, тормышта иң әһәмиятле кеше. “Әни, әнием, әнкәй” - дип назлап әйтәбез дә, күңелебездәге бөтен хис-кичерешләребезне шул гади сүзгә салабыз. Ә бит шушы өч хәрефтән торган сүзне күпме наз, җылылык һәм күңел тойгысы белән әйтәбез!

Хатын-кызның иң югары бурычы – әни булудыр, чөнки “әни” - бала әйткән беренче сүз. Бу сүз дөньяның күпчелек телләрендә бер үк төрле яңгырый һәм дөньяда иң якын, иң яраткан кешене атый.

Илебездә билгеләп үтелә торган күпсанлы бәйрәмнәр арасында хатын-кызлар көне аерым урын алып тора. Бәйрәмнең максаты – хатын-кызга сакчыл караш традицияләрен хуплау, гаилә нигезләрен ныгыту, безнең тормышта төп кешенең – әнинең, әбиләрнең әһәмиятен аеруча билгеләп үтү. Бу бәйрәм беркемне дә битараф калдыра алмый. Нәкъ хатын-кызлар көнендә үз балаларына мәхәббәт, игелек, наз бүләк итүче барлык аналарга рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Тик нинди генә җылы сүзләр әйтмәсәк тә, җитмәс төсле... Безнең һәрберебез әниебезне искә төшерергә, аңа шалтыратырга, бәлки янына кайтып, аны котларга, аның сәламәтлеге һәм кәефе ничек булуы белән кызыксынырга тиешле көн!

Мөлаем һәм ягымлы кузле, акыллы, сабыр һәм түземле, шәфкатьле, авыр вакытларда арканы сыйпаучы кадерле куллы, боз эретерлек җылы сүзле, бала өчен кайгырып, төннәрен күз йоммаучы әниләребез, сезне бәйрәмегез белән чын йөрәктән котлыйбыз. Сезгә мыклы сәламәтлек, озын гомер, рухи көч, тормыш зирәклеге, сабырлык, бәхет, гаилә уңайлыгы телибез. Безгә биргән чиксез мәхәббәтегез, назыгыз һәм кайгыртуыгыз өчен рәхмәт!

# 8 нче мартка  багышланган бәйрәм иртәләре

8 Март-балалар бакчасында иң күңелле һәм иң назлы бәйрәм! Ул иң сөйкемле, иң назлы, иң яраткан һәм иң кадерле әниләргә багышлана! Балалар бакчасында бәйрәмдә чыгыш ясау-әниләр үз балаларыннан ала алган иң яхшы бүләк.

Бәйрәм иртәләрендә әни, дәү әни турында назлы шигырьләр, җырлар яңгырады. Әниләргә биюләр багышланды.  Кызларыбызны, әниләребезне һәм әбиләребезне чын күңелдән бәйрәм белән котлыйбыз һәм нык сәламәтлек, елмаюлар телибез!

















## Яңалыклар

**12 нче март көнне Шамсутдинова Гөлгенә Раисовна районкүләмендә үткән «Уен –җитди эш» бәйгесендә катнашып икенче урынга лаек булды. Аңа алдагы көннәрдә дә зур уңышлар телибез!**





**20 нче март көнне ел саен район күләмендә уздыры-лып килүче волейбол ярышында бакчабыз хезмәткәрләре дә актив катнашты.**



Нәүрүз–татар халкының иң матур йола бәйрәмнәреннән берсе, ул көн белән төн тигезләшкән көнгә туры килә. Бу бәйрәм безнең төбәкләрдә, язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме булып санала. Ул–дуслык, киң күңеллелек, кунакчыллыкны үз эченә ала. Нәүрүз – фарсыча “яңа көн” дигәнне аңлата, икенче төрле язгы Яңа ел, дип тә әйтәләр. Бу көнне кешеләр кунак чакыралар, бер-берсенә булган үпкә-ачуларын онытарлар, җырлыйлар һәм бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар, уеннар уйныйлар. Бәйрәм хуҗасы - Нәүрүзбикә.



Балалар бакчасының зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары көн белән төн тигезләшкәндә үткәрелә торган әлеге бәйрәмне бик күңелле билгеләп уздылар. Кыш бабай белән Нәүрүзбикә “көч сынаштылар”: табышмаклар әйттеләр, биеделәр, кашыкка йомырка салып йөгерделәр. Әмма яз кызының көче күбрәк иде-ул җиңде. Кыш бабай ирешсә, тик үпкәләмәде.

